УДК 069.5

*Р.Ә. Абзалина*

# ТАТАРСТАН МИЛЛИ МУЗЕЕ ЯДКӘРЛӘРЕННӘН: ХӨТБӘ ТАЯКЛАРЫ

В статье описываются четыре экспоната, хранящиеся в фондах Национального музея Республики Татарстан: палки-посохи для хутбы Шигабуддина Марджани (1818–1889) и Шакирджана Файзуллина (1819–1916) – имама мечети деревни Починок Сосна, отчима татарского поэта Габдуллы Тукая, дорожная палка татарского просветителя Габделкаюма Насыри (1825–1902) и палочка из камыша, принадлежавшая Мухаммадзакиру Габделвахабову-Камалову (1818–1893) – четвертому имаму Чистопольской мечети, деду со стороны матери Равиля Амирханова (1946–2006).

Вместе с тем в статье описывается значение палки-посоха в мусульманской практике, история появления данных экспонатов в музее со сведениями не только о владельцах, но и о тех, кто приложил усилия для их сохранения. В статье приводятся транскрипция и перевод с арабского языка на татарский надписей с палки Ш. Файзуллина, выполненные сотрудником Национального музея А. Кадыровым.

**Ключевые слова:** Национальный музей, палка для хутбы, Ш. Марджани, К. Насыри, Шакирджан Файзуллин (отчим Тукая), Закир ишан

The article describes four sticks kept in the collections of the National Museum of the Republic of Tatarstan: the hutba stick of Shigabuddin Marjani, the stick that Shakirjan Fayzullin (1819–1916), the stepfather of the Tatar poet Gabdulla Tukai (1886–1913), the travel stick of the Tatar educator Gabdelkayum Nasyri (1825 1902), and a reed stick, it belonged to Mukhammadzakir Gabdelvakhabov-Kamalov (1818–1893)– the fourth imam of the Chistopol mosque – the maternal grandfather of Ravil Amirkhanov (1946–2006). At the same time, the article describes the significance of the staff in Muslim practice, the history of these exhibits in the museum, and information not only about their owners, but also about those who made efforts to preserve them. As an appendix, the article provides a translation of the inscriptions on Sh. Fayzullin's staff in Arabic, translated into Tatar by A. Kadyrov.

**Keywords:** National Museum, khutba stick, Sh. Marjani, K. Nasiri, Tukay's stepfather, Zakir Ishan,

Татарстан Республикасы Милли музеенда татар галимнәре һәм имамнары белән бәйле ядкәрләр арасында дүрт кызыклы экспонат – Шиһабеддин Мәрҗани (1818–1889) һәм Балтач районы Сасна Пүчинкәсе авылы имамы Мөхәммәдшакир Фәйзуллинның (1819–1916) хөтбә таяклары (ТР ММ 8574; 18457/1), Каюм Насыйриның (1825–1902) мөселманнар таянып йөри торган гади юл таягы (ТР ММ 24770-1) һәм Закир ишанның камыш таягы (ТР ММ25723) саклана.

Ш. Мәрҗанинең хөтбә таягын аның оныгы – Зәйнәп Абдулла кызы Апанаева – 1945 елның 28 августында, музейда татар әдәбиятына багышланган экспозиция төзү эше башлангач, хезмәткәрләр

соравы буенча тапшыра. Аңа кадәр таяк Казанда Иске татар бистәсенең Комсомольская (хәзерге Ш. Мәрҗани) урамындагы 44 йортта сакланган. Аның озынлыгы – 142 см, кул тоткасы – 22 см, агачтан сырлап эшләнгән. Аскы өлештәге 14 сантиметры – диаметры 7 миллиметр булган корыч тимердән. Шул корыч таякның өске өлешендәге 106 сантиметрына каен тузыннан кисеп алынган дисклар (якынча 1166 данә) киертелеп, өсте балавыз агызып шомартылганга охшап тора. Астагы тимер өлеше һәм кул тоткасына карап, аны, кирәк вакытта, юлда таянып йөрергә яраклаштырылган дип әйтеп була. 1858 елда Ш. Мәрҗани үзе төзеткән һәм соңгы көннәренә кадәр яшәгән йорт (Каюм Насыйри урамы, 10) мәчеттән урам аркылы гына урнашкан була. Таяк астындагы очлы корыч тайгак вакытларда урамда йөрү өчен дә уңайлы булгандыр.

Мәгърифәтче галим Габделкаюм Насыйри (1825–1902) сөннәт буенча таякка, кайвакыт хәтта зонтка да таянып йөргән. Аның таягын, Каюм Насыйриныкы дигән риваять белән, энесе Габделкави кызы Разия Хөсәенованың кызы Бәрра Бариева 1999 елның мартында галимнең Казандагы музеен оештырганда тапшыра. Таякның озынлыгы – 95, диаметры 2 см. Буеннан буена көйдереп бизәлгән. Ботакларының күзле буынтыклары – 13. Ныклыгы һәм төрле җирдә булган ярыклары буенча, бу таяк артыштан ясалган дип билгеләдек. Ш. Мәрҗани таягындагы каен тузын, аскы өлешендәге тимер таягының корычтан ясалганлыгын, К. Насыйри таягының артыш агачыннан икәнлеген ачыкларга Милли музейның агач эшләнмәләр буенча мөхтәрәм остасы Роман Васильевич Хашев (1971 елда туган) ярдәм итте.

Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музее экспозициясендә даими тамашага куелган хөтбә таягы (18457/1) – Габдулла Тукайның үги әтисе Балтач районы Сасна Пүчинкәсе авылы имамы Мөхәммәдшакир Фәйзуллин хәзрәтнеке (1819–1916). Аны 1981–1982 елларда Тукай-Кырлай музееның директоры (1978–1983) Борис Фёдорович Антонов музейны тулыландыру максаты белән махсус оештырылган экспедиция вакытында табып ала. Әлеге экспедиция Малмыж янындагы ике мәчете дә сакланып калган Йөрек авылында башлана. Ниятләре – Кырлай мәчетен дә музей комплексына кертеп яңартып эшләү өчен, борынгыдан сакланып калган типологик чын мәчетне өйрәнеп кайту. «Йөрекнең партком секретаре Җәүдәт исемле кеше авыл халкының бик итагатьле, диндар булуын, өлкәннәрнең барысының да (хәтта үзенең дә) мәчеткә йөрүен, югыйсә, үзенә төртеп күрсәтүләреннән уңайсызлануын сөйләп, 90 яшьлек Гайнан исемле указлы муллага алып китте», – ди Б. Антонов үзенең бу турыдагы мәкаләсендә [1]. Алар Йөрек мәчетенең бөтен сызымнарын төшерәләр, ислам атрибутикасы булган комган, шәмаилләр, хәтта мулланың Бохарадан кайтартылган иске чапан, чалмасына кадәр алып кайталар. Йөрек мулласы Гайнан хәзрәт аларны: «Саваплы, Аллаһ кушкан эш белән йөрисез икән, миннән фатиха», – дип, үзе дога кылып озата. Юл уңаенда, Мөхәмматшакир мулла яшәгән авылданиләр калганын күрәселәре

килеп, Балтач районы Сасна Пүчинкәсе авылына да керәләр. Авылга кергәч беренче очраган кеше, аларның кем булуларын аңлап, нишләп йөрүләрен белгәч, бүрәнәдән салынган өр-яңа йортка күрсәтеп: «Әнә шуларга керегез, мулла таягы шунда яши», – ди. «Урта яшьләрдәге ир белән хатын чәй эчеп утыралар. Хатыны сыер савучы, әле генә иртәнге савымнан кайткан, ә ире тракторчы – әле эшкә китәргә өлгермәгән. (Кунакчыл, күркәм кешеләр, сез инде хәзер әби-бабайдыр, исемнәрегезне якынча да исемә төшерә алмыйм.) Чәй янында сөйләшә киткәч, хатыны җәһәт кенә чормаларыннан киндер чүпрәккә кат-кат төрелгән бер таяк алып төште. Рәвеш-кыяфәтеннән үк күренеп тора: борынгы таяк, тарихның үзе! Буынтыклы-буынтыклы, мамыктай җиңел таякны кулга алам. Буеннан-буена гарәпчә нидер язылган. Кемнеке булуын, кайчангы икәнен сорашам. Хуҗа әллә ни күп сөйли алмады, әллә белеп тә әйтергә теләмәде. Ул заманда кешеләр нәсел тамырлары турында ачылып сөйләргә куркалар яки оялалар иде. Шуны аңладым: әлеге таяк Мөхәммәдшакир мулланыкы булган. Бәлки әле аның эти-бабаларыннан ук калгандыр. Әңгәмәдәшемнең этисе шулай сөйли торган булган.

– Этиеңә ничек килеп кергән? Ул мулла идеме?

– Юк ла, – ди уңайсызланып, – авылда динне белүче бүтән кеше калмагач, болай гына мулла булып йөрде. Үлем-китемнәр, балаларга исем кушулар. Таякны аңа чын мулла үлгәч биргәннәр. Ул аның белән урамга чыкмады. Бу бик борынгы, гыйлемле муллалардан калган изге таяк дип сөйли торган иде. Сандыкта кадерләп кенә саклады», – дип яза Б. Айтуганов [1].

Хөтбә таягына түбәндәге дини төшенчәләр-тәгъбирләр язылган: истигазәдән соң ислам диненең төп китаплары: Инҗил, Зәбур, Коръән, Аллаһның исем-сыйфатларын белүнең зарурлыгы, тәүбә-истигъфарның мөһимлеге, юмартлык һәм киң күңеллелек, тормыш китергән сынауларга сабырлык, Аллаһның рәхмәтенә ризалык күрсәтү, авырлыклар килгәндә тормышны каһәрләүдән тыелу, Аллаһны мактау һәм шөкер итү.

Шулай итеп, имам, халыкка вәгазь-хөтбә укырга чыкканда, беренче чиратта үзен нәсыйхәтләп тәрбияли. Шул дәрәҗәгә ирешкән, шуларны кабул иткән кешенең генә халык тәрбияләргә хакы була.

Музей документларында экспедициянең төгәл вакыты (1981 елның 29 августыннан 2 сентябрьгә кадәр), Мөхәммәдшакир хәзрәт Фәйзуллинның Арча районы Мөндеш авылында туып, Кышкар мәдрәсәсендә белем алуы, Сасна Пүчинкәсе яки Кече Сасна дигән авылда имам булуы (хәзер Балтач районына керә), Тукайның әнисе Мәмдүдә абыстай белән 1888 елның 22 декабрендә никахлашуы, бу вакыт кияүнең – 40, кәләшнең 23 яшьтә булуы – бары да теркәлгән. Таякны күп еллар үзләрендә саклаган йорт хуҗасы Гайнанов Фаяз Гайнан улы (1928–1998), хатыны Миңҗамал Мөхәммәтшаһи кызы да (1928–2005), үзләренең нинди кадерле әйбер саклауларын белеп, шулай да музейга һәм музей хезмәткәренә ихлас ышаныч күрсәтеп,

әлеге таякны гына түгел, стена сәгатен һәм XX йөз башында яратып киелгән бер бишмәтне дә биреп җибәрәләр.

Хәзерге көндә бу йортта гаиләсе белән уллары Фаязов Әхмәт Фаяз улы яши: «Казан музеена баргач: "Бу безнең өйдәге таяк бит дип", – сөенеп карап торган идем. Таякны 1963 елда мәчетне сүткән вакытта, чормада, кеше күзенә күренмәслек җирдән, кәрниздә хасиятләп төрелгән килеш табып алалар һәм, мәчет бүрәнәләрен күрше Субаш авылына мәктәп итеп күчереп салыр өчен алып киткәндә, авылның ышанычлы кешесе Гайнан Мөхәмммәтгали улына (1889–1976) – минем бабайга сакларга тапшыралар. Субашта 1991 елда яңа мәктәп салынгач, мәчет бүрәнәләрен яңадан урынына – Сасна Пүчинкәсенә алып кайтып, мәчетне яңадан торгызалар. Яңа төзелгән мәчеткә мөнбәрне һәм мулла таягын яңадан үзем кырлап ясадым», – дип, үзенең фикерен дә җиткерде. Бу гаиләнең нәсел очын табарга булышкан рәссам, педагог Таһир Ильясовка да зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Бу төбәк белән бәйләнешле тагын бер таякның тарихы кызыклы.

XX гасыр ахыры – 90 нчы елларда археограф галим, әдәбият белгече Марсель Әхмәтҗанов (1939–2025) Институтта музей өчен кызыклы экспонат булырлык әйбер саклануын әйтеп, үзенә чакырды. Ул вакытта Мирасханә (ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге) Ленин (хәзерге Кремль) урамында иде. «Кичә Равил Әмирханов[1] Чистайдан Закир бабасының камыш таяк кисәген алып кайткан, сиңа бирергә кушты», – диде. Эштән кайтышлый кереп, таякны өйгә үк алып кайтып киттем. Марсель абый: «Онытырсың, иртәгә кереп алырсың», – дисә дә, тыңламадым. Берничә айдан өйдә гел эчем поша башлады... Бер укымышлы апага садака бирергә барып, сөйләп күрсәткәч: «Синең өеңдә сездә булырга тиеш түгел әманәтле әйбер бар. Шуны табып, урынына илтеп куй», – диде. «Кешедән китап алып торабыз, кайтарырга онытабыз», – дим. «Юк, бу китап кына түгел, бик зур әйбер», – ди. «Ничек табыйм икән?» – дим. «Өеңнең һәр почмагына "Әлхәм", "Ихлас", "Фәләкъ", "Нас", "Аятел-көрси" укып кил, табарсың», – ди. Кечкенә бүлмәдә китап киштәсенең иң өске шүрлегендә газета кәгазенә төреп куйган камыш таяк шулай табылды да.

Закир ишан Камалов, Чистай имамы булса да, чыгышы белән нәкъ шул Сасна авылыннан. «Чистайлы Әмирханнарның рухи тарихы, бигрәк тә XIX йөз азакларында, Габделваһаповлар ыруы (Камаловлар) белән нык береккән. Шуңа күрә сүзне шул нәселнең умыртка баганасы – әтиебезнең әнисе ягыннан бабасы Закир ишаннан (Мөхәммәтзакир Габделваһапов-Камалов) (1818–1893) башлап җибәрү шарт. <...> Мөхәммәдзакир Камалов Мәчкәрә мәдрәсәсен тәмамлый, муллалыкка указ ала, 1846 елның 17 сентябрендә Казан губерна идарәсе тарафыннан Чистай мәчетенә имам-хатыйп итеп билгеләнә. "Мелла

[1] Тарихчы, тарих фәннәре докторы Равил Госман улы Әмирханов (1946–2006).

Закир бине Габделваһаб бине Габделкәрим әс-Саснавый. Тумышы белән Малмыж өязенең Сасна исемле зур авылыннан, сәүдәгәр баласы. Мәчкәрәдә мелла Габдулла бине Яхъя һәм Саснада мелла Таҗеддин бине Габдеррәшит әл-Иштирәкиләрдән гыйлем алып, бу шәһәргә (Чистайга) имам булды. Мелла Мәхмүд бине Мөхәммәд бине Садыйк бине Мостафа әд-Дагыстаныйга таянып, аның ышанычын яулады", диелә "Мөстәфадел-әхбар"дә» [2].

Ш. Мәрҗани мәгълүматы буенча, Чистай мәчете Хәсән бине Муса бине Якуб әс-Саснавый хаҗи тарафыннан салдырылган [4: 154].

Хәсән бине Муса бине Якуб әс-Саснавый (1784–1867) Сасна зиратында җирләнгән. Аның бердәнбер улы Гомәр Чистай мулласы Закир ишан кызына өйләнә һәм Казанда шактый зур байлардан исәпләнә. Аның улы Яһүдә бине Гомәр Чистай мәчетенең беренче имам-хатыйбы, ахун да булып торса, Закир бине Габделваһаб бине Габделкәрим әс-Саснавый – Чистай мәчетенең дүртенче имамы.

Чистайдан Равил Әмирхановның бабасы Хөсәен Әмирханның (1814–1893) Нәҗип исемле икенче улы исә Чистайның Мөхәммәдзакир ишан кызына никахланып, аның янында имам вә мөдәррис булган. Алда әйтеп үтелгән мәгълүматлар Закир ишан таягының ни рәвешле Равил Әмирхановка нисбәтле булуын дәлилли. Бу ике таяк Сасна авылларына барып тоташа. «Балтач төбәгендә хәзер Сасналар икәү. Берсе – Зур, икенчесе Сасна Пүчинкәсе – аерылып чыккан авыл. Шуңа күрә Мәмдүдә абыстайны зиярәт кылучылар Зур Саснага барып эзләп йөриләр», – диде Әхмәт Фаязов. Хөтбә таягы да, бәлки, XIX гасыр уртасында зур авылдан бу авылга нигез салган бабайлар белән бергә күчкәндер.

Гомумән, музей фондларында сакланган мондый уникаль экспонатлар мәшһүр галимнәребезне, аларның тәрҗемәи хәлен, халкыбызның мәдәни мирасын өйрәнү өчен дә кыйммәтле чыганак булып торалар. Алга таба да андый ядкәрләр табылыр дигән өметтә калабыз.

Таяктагы язуларны Татарстан Республикасы Милли музее хезмәткәре, гарәп теле белгече Альберт Кадыйров укыды. Тәрҗемә һәм язуларны төгәл гарәп хәрефләре белән бирү өчен, аның тасвирламасын биредә тулысы белән китерәбез.

## ИМАМ / МУЛЛА ТАЯГЫ
XIX гасыр уртасы
*ТР ММ 18457-1*

Агачтан ясалган имам / мулла таягы. Таякта буяу белән кулдан язылган гарәпчә сүзләр бар. Кайбер сүзләр сөртелеп бетеп, укылмый:

1) Таяк тоткычында:

أعوذ بالله من الشيطان الرجيم – тәрҗ. Бөтен җирдән куылган шәйтаннан Аллаһка сыенам.

بسم الله الرحمن الرحيم – тәрҗ. Рәхимле һәм миһербанлы Аллаһ исеме белән.

الإنجيل والزبور و القرآن – тәрҗ. Инҗил һәм Зәбур һәм Коръән.

2) Шуннан, таякның буеннан-буена, өстән аска, уңнан сулга (гарәп язуында) гарәпчә түбәндәге җөмләләр язылган:

أولا علم بأسماء و صفات – тәрҗ. Иң әүвәл – исем һәм сыйфатларны белү (Аллаһның исем һәм сыйфатларын. – *А.К. искәрмәсе*).

ثانيا التوبة و الإستغفار – тәрҗ. Икенчедән – тәүбә һәм истигъфар.

ثالثا (؟) التجرد عن الدنيا – тәрҗ. Өченчедән – (?) дөньядан ваз кичү.

و رابعا (...؟) عن الخلق – тәрҗ. Дүртенчедән – … мәхлуклардан (?).

والخامس المخاربة الشيطان – тәрҗ. Бишенче – шәйтан белән көрәш алып бару.

و التاسع البر و التنزول – тәрҗ. Тугызынчы – юмартлык һәм киң күңеллелек.

و العاشر الصبر عند النزول القضاء – тәрҗ. Унынчы – тормыш китергән сынауларда сабырлык.

والحادي عشر رضاء من (؟) رحمة الله – тәрҗ. Унбер – Аллаһ рәхмәтенә (?) ризалык күрсәтү.

والثانى عشر (؟) أكوف (؟) من قهر سوء عقوبة – тәрҗ. Уникe – башка төшкән (?) авырлыклар сәбәпле (?) тормышны каһәрләүдән тыелу.

والرابع عشرالحمد والشكر – тәрҗ. Ундүрт – мактау (Аллаһны мактау. – *А.К. искәрмәсе*) һәм шөкер итү.

**Әдәбият**


1. *Айтуганов Б*. Мулла таягы // Татарстан яшьләре. 2006. 12 гыйнвар. Б. 7.
2. *Әмирхан Р.* Әмирханнар. Казан: Мәгариф, 2005. 223 б.
3. *Каюм Насыйри.* 1885 ел өчен календарь. Казан: Казан ун-ты басмасы, 1884.
4. *Марджани Шигабутдин* (1818–1889). Полезные вести о состоянии Казани и Булгара (Мустафад ал-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар) / пер. со старотатарского, арабского и сост. науч. коммент. – Р.К. Адыгамов. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. 271 с.
5. *Мөслими.* Тәварихы Болгария (Болгар тарихы). Казан: Иман, 1999. 100 б.



***Абзалина Рәмзия Әсрареддин кызы,***
*Татарстан Республикасы Милли музее*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

***Абзалина Рамзия Асраровна,***
*старший научный сотрудник*
*Национального музея Республики Татарстан*

*globus54@list.ru*